ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

ПРИКАЗ

01.11.16 г. Казань № 102-од

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына керүче гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ уздыру тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсен үзгәртеп кору мәсьәләләре» 2016 елның 31 маендагы № УП-491 Указын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2016 елның 9 августындагы № 541 карарын бастырып чыгаруга бәйле рәвештә б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына керүче гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ уздыру тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының структур бүлекчәләре җитәкчеләре Тәртипнең һичшиксез үтәлешен тәэмин итәргә тиеш.

3. Хокук һәм кадрлар эше бүлеге әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәүне тәэмин итәргә тиеш.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенә кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ уздыру тәртибен раслау турында» 2015 елның 13 июлендәге № 048 боерыгының үз көчен югалтуын танырга.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис И.Х. Әюпова

Башкаручы:
хокук һәм кадрлар
эше бүлегенең өлкән белгече Н.Н. Гыймадетдинова

Килештерелде:
хокук һәм кадрлар
эше бүлеге башлыгы В.Г. Миңнеәхмәтова

Рәис урынбасары Ю.И. Әдһәмова

Рәис урынбасары Р.А. Шәйхетдинова

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт комитетының
2016 елның 1 ноябрендәге № 102-од
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт комитетына
керүче гражданнар мөрәҗәгатьләренә
анализ уздыру
тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәмләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына керүче гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ уздыру тәртибен (алга таба – Тәртип) гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшен камилләштерү, аларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын арттыру максатларында эшләнде.

1.2. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына (алга таба – Дәүләт комитеты) кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау Дәүләт комитетына, шулай ук аның ведомствосындагы учреждениеләргә кергән барлык мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

## II. Дәүләт комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ уздыру тәртибе

2.1. Мөрәҗәгатьләрне анализлау елына ике мәртәбә уздырыла: яртыеллык өчен һәм узган ел өчен.

2.2. Дәүләт комитетының структур бүлекчәләре җитәкчеләре, аның ведомствосындагы учреждениеләр агымдагы елда кергән мөрәҗәгатьләр турындагы мәгълүмати-аналитик һәм статистик материалларны – агымдагы елның 25 декабреннән дә соңга калмыйча, шулай ук яртыеллык өчен хисапларны агымдагы елның 25 июненнән дә соңга калмыйча Дәүләт комитетының Эшләр башкару һәм оештыру эше секторына тапшырырга тиеш.

2.3. Гражданнар мөрәҗәгатьләрнә анализ уздыру Дәүләт комитетының эшләр башкару һәм оештыру эше секторы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.4. Дәүләт комитетының Эшләр башкару һәм оештыру эше секторы тапшырылган мәгълүмати-аналитик һәм статистик материалларны гомумиләштерү һәм анализлау нәтиҗәләре буенча аналитик белешмә төзи. Белешмә проекты Дәүләт комитеты рәисенең шушы эшләрне алып баручы урынбасарына җибәрелә.

2.5. Аналитик белешмәдә кергән, башка адресларга җибәрелгән һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләрнең саны турындагы, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турындагы, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны турындагы, гражданнарны шәхсән кабул итү һәм шәхсән читтә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турындагы, мөрәҗәгатьләр тематикасы турындагы, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турындагы мәгълүмат, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм бүтән актлар (булса) турындагы мәгълүмат булырга тиеш.

2.6. Агымдагы елның 30 июненнән һәм 30 декабреннән дә соңга калмыйча әлеге аналитик белешмә Дәүләт комитетының рәисе карасын өчен Дәүләт комитетының Эшләр башкару һәм оештыру эше секторы мөдиренә тапшырыла һәм Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыру өчен Дәүләт комитетының Архив тармагын мәгълүматлаштыру секторына җибәрелә.

2.7. Аналитик белешмә Архив тармагын мәгълүматлаштыру секторы белгечләре тарафыннан аналитик белешмәне алганнан соң өч эш көне эчендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Дәүләт комитетының рәсми сайтының www.arhiv.tatarstan.ru "Гражданнар мөрәҗәгатьләре" бүлегендә урнаштырыла.